**СОВЕТ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ**

Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы, 423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советы
КАРАРЫ

2022 елның «29» декабреннән № 30-237

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында»гы 2015 елның 18 мартындагы 42-247 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советы карары проекты хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 44 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 7 статьясы, «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставының 91, 92 һәм 93 статьялары нигезендә, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Яңа Чишмә муниципаль районы Советының 2015 елның 18 мартындагы 42-247 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына (№2-9, 16.10.2015 ел, №9-32,11.02.2016 ел, №18-82, 28.09.2016 ел, №20-103, 14.12.2016 ел, №25-132, 17.04.2017 ел, №28-150 17.08.2017 ел, №31-180, 14.12.2017, №37-209, 25.05.2018 ел, №43-252, 13.12.2018, №50-299, 05.07.2019, №61-378, 04.06.2020 ел, №10-70, 02.06.2021ел, №16-124, 09.12.2021, №24-181 от 7.07.2022 ел карарлары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 13 (1) статьяның 3 пунктындагы өч пунктчасында «район сайлау комиссиясе» сүзләрен «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә районы территориаль сайлау комиссиясе (алга таба – территориаль сайлау комиссиясе)» сүзләренә алмаштырырга;

1.2. 13 (1) статьяның 4 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. 3. Муниципаль сайлауларны әзерләү һәм үткәрү сайлау комиссияләренә аларның компетенциясе кысаларында йөкләнә.»;

1.3. 13 (2) статьяның 5 пунктында «Район сайлау комиссиясе» сүзләрен" «территориаль сайлау комиссиясе» сүзләренә алмаштырырга;

1.4. 13 (2) статьяның 8 пунктындагы беренче җөмләдә «Район сайлау комиссиясе» сүзләрен «территориаль сайлау комиссиясе» сүзләренә алмаштырырга;

1.5. 13 (2) статьяның 8 пунктындагы икенче җөмләдә «Район сайлау комиссиясе» сүзләрен «территориаль сайлау комиссиясе» сүзләренә алмаштырырга;

1.6. 13 (2) статьяның 12 пунктындагы беренче җөмләдә «Район сайлау комиссиясе» сүзләрен «территориаль сайлау комиссиясе» сүзләренә алмаштырырга;

1.7. 19 статьяның 5 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә::

«5. Гавами тыңлаулар уздыру вакытын һәм аларны уткәрү урынын күрсәтеп, гавами тыңлауларга чыгарыла торган муниципаль норматив хокукый акт проекты, гавами тыңлаулар уткәрү көненә кадәр 7 календарь көннән дә соңга калмыйча, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Порталында Яңа Чишмә муниципаль районы Порталының рәсми сайтында бастырып чыгарылырга (халыкка җиткерелергә) тиеш: http://novosheshminsk.tatarstan.ru, Яңа Чишмә муниципаль районы торак пунктлары территориясендә махсус мәгълүмат стендларында, шулай ук «Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (муниципаль хезмәт күрсәтүләр) порталы» федераль дәүләт мәгълүмат системасында урнаштырылырга тиеш;

1.8. 19 статьяның 6 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә::

«6. Гавами тыңлаулар һәм муниципаль норматив хокукый акт проекты басылып чыккан (халыкка җиткерелгән) көннән башлап, Яңа Чишмә муниципаль районы халкы район Башлыгына муниципаль норматив хокукый акт проекты буенча, гавами тыңлауларга чыгарылган, шул исәптән «Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталы» федераль дәүләт мәгълүмат системасы аша, тәкъдимнәр һәм искәрмәләр җибәрергә хокуклы.

Кисәтүләр һәм тәкъдимнәр җибәрү гавами тыңлаулар уткәрү көненә кадәр 2 эш көненнән дә соңга калмыйча тәмамлана.

Яңа Чишмә муниципаль районы Башлыгы кергән тәкъдимнәрне һәм кисәтүләрне берләштерүне оештыра һәм аларны гавами тыңлауларда катнашучыларга җиткерә.»;

1.9. 19 статьяның 9 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«9. Гавами тыңлауларның нәтиҗәләре «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында: http://novosheshminsk.tatarstan.ru, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы торак пунктлары территориясендә һәм «Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталы» федераль дәүләт мәгълүмат системасында гавами тыңлаулар уздырганнан соң 5 эш көненнән дә соңга калмыйча басылып чыгарга (халыкка җиткерелергә) тиеш»;

1.10. 8 бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «территориаль сайлау комиссиясе»;

1.11. 59 статьяның исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә :«территориаль сайлау комиссиясе»

1.12. 59 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Территориаль сайлау комиссиясе муниципаль сайлауларны, җирле референдумны, депутатны чакыртып алуны, депутат, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасы, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи заты буенча тавыш бирүне әзерләүне һәм уздыруны әзерли. Җирле референдум уздырганда территориаль сайлау комиссиясе референдум комиссиясе сыйфатында эш итә.

2. Территориаль сайлау комиссиясе җирле үзидарә органнары структурасына керми һәм даими нигездә эшли торган муниципаль орган булып тора.

3. Территориаль сайлау комиссиясенә Татарстан Республикасы Законы буенча юридик зат статусы бирелергә мөмкин.

4. Территориаль сайлау комиссиясе федераль закон, Татарстан Республикасы Сайлау кодексы билгеләгән тәртиптә төзелә.

Территориаль һәм участок сайлау комиссияләре Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасында, Татарстан Республикасы закон чыгару органында депутат мандатларын бүлешүгә кертелгән кандидатлар исемлекләрен күрсәткән сәяси партияләрнең тәкъдимнәре нигезендә төзелә. Күрсәтелгән сайлау комиссияләрен формалаштыру шулай ук башка сәяси партияләр һәм башка иҗтимагый берләшмәләр тәкъдимнәре нигезендә гамәлгә ашырыла;

5. Җирле үзидарә органнарына сайлаулар буенча территориаль һәм участок сайлау комиссияләре әлеге статьяның 4 пунктында күрсәтелгән тәкъдимнәр, шулай ук муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органында депутат мандатларын бүлешүгә кертелгән кандидатлар исемлекләрен күрсәткән сайлау берләшмәләренең тәкъдимнәре нигезендә төзелә.

6. Территориаль сайлау комиссиясенең вәкаләтләре вакыты биш ел тәшкил итә. Әгәр территориаль сайлау комиссиясенең вәкаләтләре чоры сайлау кампаниясе чорында, референдум билгеләнгәннән соң һәм шушы комиссия катнаша торган референдум кампаниясе тәмамланганчы узса, аның вәкаләтләре чоры шушы сайлау кампаниясе, референдум кампаниясе тәмамланганчыга кадәр озайтыла.

7. Территориаль сайлау комиссиясе хәлиткеч тавыш хокукына ия булган сигез әгъзадан төзелә.

7. Участок сайлау комиссиясе хәлиткеч тавыш хокукына ия булган 6 әгъзадан тора. Җирлекнең участок сайлау комиссиясе әгъзалары саны муниципаль берәмлек уставы белән билгеләнә.

8. Территориаль сайлау комиссиясенең вәкаләтләре, аның эшчәнлеге тәртибе һәм гарантияләре федераль законнар, Татарстан Республикасы законнары һәм район Уставы белән җайга салына.

9. Җирле үзидарә органнарына сайлаулар әзерләү һәм уздыру, автоматлаштыру чараларын эксплуатацияләү һәм үстерү, сайлауларны оештыручыларны һәм сайлаучыларны укыту белән бәйле чыгымнар бу максатларга җирле бюджеттан бүлеп бирелгән акчалар хисабына территориаль сайлау комиссияләре тарафыннан башкарыла. Күрсәтелгән чыгымнарны финанслау җирле бюджет чыгымнарын бүлү турында расланган бюджет язмасы нигезендә, сайлаулар билгеләү турындагы карар рәсми басылып чыккан (бастырылган) көннән ун көннән дә соңга калмыйча, башкарыла.».

2. «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына кертелә торган үзгәрешләр проектына тәкъдимнәрне исәпкә алу тәртибен кушымта нигезендә расларга.

3. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының 2015 елның 18 мартындагы 42-247 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советы карары проекты турында» Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының әлеге карар проектын кабул итәргә һәм гавами тыңлауларга чыгарырга.

4. Татарстан Республикасының Яңа Чишмә муниципаль районы Советының 2015 елның 18 мартындагы 42-247 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасының Яңа Чишмә муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында» карары проекты буенча 2023 елның 15 гыйнварында сәг. 17.00 дә Татарстан Республикасы, Яңа Чишмә районы, Яңа Чишмә авылы, Совет урамы,80 йорт адресы буенча урнашкан Яңа Чишмә муниципаль районы Советының актлар залында гавами тыңлаулар үткәрергә.

Гавами тыңлаулар тәртибе Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының 2021 елның 30 сентябрендәге 14-105 номерлы карары белән расланган, Татарстан Республикасының «Интернет» мәгълүмат - телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат порталының рәсми сайтында http://prvo.tatarstan.ru 2021 елның 30 сентябрендә бастырылган Яңа Чишмә муниципаль районының халык алдында тыңлаулар турындагы нигезләмәгә туры китереп гамәлгә ашырыла.

5. Яңа Чишмә муниципаль районы Советының оештыру бүлегенә ачык тыңлаулар үткәрүне, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының

күрсәтелгән карары проекты буенча гражданнар тәкъдимнәрен кабул итүне һәм исәпкә алуны тәэмин итәргә.

6. Законлылык, хокук тәртибе һәм җирлекләрнең вәкиллекле органнары белән үзара хезмәттәшлек буенча даими комиссиягә гавәми тыңлауларда яңгыраган һәм фикер алышу барышында кергән тәкъдимнәрне исәпкә алып, Яңа Чишмә муниципаль районы Советы карары проектын эшләп бетерергә һәм Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советы утырышына кертергә.

7. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат – телекоммуникация челтәрендә «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталы»нда: http://pravo.tatarstan.ru «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында: http://novosheshminsk.tatarstan.ru бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы торак пунктлары территориясендәге махсус мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

8. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тоту Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының законлылык, хокук тәртибе һәм җирлекләрнең вәкиллекле органнары белән хезмәттәшлек буенча даими комиссиясенә йөкләнә.

Яңа Чишмә муниципаль районы Башлыгы В. М. Козлов

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының 2022 елның «29» декабреннән 30-237 номерлы карарына кушымта

«Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына кертелә торган үзгәрешләр проектына тәкъдимнәрне исәпкә алу тәртибе

1. «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына кертелә торган үзгәрешләр проектына тәкъдимнәр Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советына түбәндәге адрес буенча: 423190, Татарстан Республикасы, Яңа Чишмә районы, Совет урамы, 80 йорт, каб. № 314 язма рәвештә Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының оештыру бүлеге җитәкчесенә тапшырыла.

Тәкъдимнәр «Интернет» мәгълүмат – телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында http://novosheshminsk.tatarstan.ru халыкка җиткерелгән көннән алып эш көннәрендә 08.00 сәгатьтән 16.30 сәгатькә кадәр кабул ителә.

2. Ачык тыңлауларда чыгыш ясау хокукы белән катнашу өчен гаризалар түбәндәге адрес буенча кабул ителә: 423190, Татарстан Республикасы, Яңа Чишмә районы, Яңа Чишмә авылы, Совет урамы, 80 йорт, каб. № 314 шәхсән яки почта аша (конвертында«Устав турында фикер алышу» тамгасы белән).